| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Азнакай районының Чәкән авылындагы Базарлы урамы;

Әтнә районының Күшәр авылындагы Салих Сәйдәшев урамы;

Лениногорск районының Иске Куак авылындагы Заварыкин урамы;

Мөслим районының Метрәй авылындагы Кооператив урамы;

Мөслим районының Сикия авылындагы Кызыл Яр урамы;

Теләче районының Айдар авылындагы Ленин урамы;

Бөгелмә шәһәренең Бауман урамындагы 14 нче йортның өй яны территориясе;

Зәй районының Иске Пәлчикәү авылы янындагы, «Зәй» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

«Шәһәр яны урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе Матюшино участок урманчылыгының 82 нче кварталында урнашкан «Залив – ял базасы» кулланучылар кооперативы территориясе.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Азнакай районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 30 сентябрендәге ПУ-942 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 7 октябрендәге ПУ-974 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 9 октябрендәге ПУ-978 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-985 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 17 декабрь
№ ПУ-1222